**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 28 ноябрь № 877

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 декабрь, 1063 нче; 2015 ел, 8 май, 333 нче; 2015 ел, 17 июнь, 444 нче; 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы; 2016 ел, 30 март, 181 нче; 2016 ел, 25 май, 349 нчы; 2016 ел, 13 сентябрь, 640 нчы; 2016 ел, 21 сентябрь, 670 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Ярдәмче программалар исемлеге» юлына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«7. Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкенең социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт»;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Программаны тормышка ашыруга бюджет ассигнованиеләре күләмнәре 232 337 984,92 мең сум тәшкил итә, шул исәптән |

| | |
|---|---|
| | түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 30 831 624,92 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 3 276 380,30 мең сум);<br>2015 ел – 40 418 421,5 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 10 270 614,50 мең сум);<br>2016 ел – 49 120 175,3 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 19 328 400,20 мең сум);<br>2017 ел – 27 991 940,80 мең сум;<br>2018 ел – 27 991 940,80 мең сум;<br>2019 ел – 27 991 940,80 мең сум;<br>2020 ел – 27 991 940,80 мең сум* |

* Финанслау күләмнәре, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, фараз характерында була.»;

Программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «3. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Программаны тормышка ашыруга бюджет ассигнованиеләре күләмнәре 232 337 984,92 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 30 831 624,92 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 3 276 380,30 мең сум);

2015 ел – 40 418 421,5 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 10 270 614,50 мең сум);

2016 ел – 49 120 175,3 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 19 328 400,20 мең сум);

2017 ел – 27 991 940,80 мең сум;

2018 ел – 27 991 940,80 мең сум;

2019 ел – 27 991 940,80 мең сум;

2020 ел – 27 991 940,80 мең сум.

Программаны тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, фараз характерында була.»;

Программага 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

«2014 – 2020 елларга мәктәпкәчә белем бирүне, инклюзив белем бирүне кертеп, үстерү һәм бу өлкә хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программа чараларын финанслау күләме 38 187 588,18 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 5 207 196,08 мең сум;<br>2015 ел – 5 613 039,50 мең сум;<br>2016 ел – 6 028 982,60 мең сум;<br>2017 ел – 5 334 592,50 мең сум;<br>2018 ел – 5 334 592,50 мең сум;<br>2019 ел – 5 334 592,50 мең сум;<br>2020 ел – 5 334 592,50 мең сум* |

* Финанслау күләмнәре, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, фараз характерында була.»;

ярдәмче программаның 2 бүлегендә 5, 13 нче пунктлар үз көчен югалткан дип санарга;

ярдәмче программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3. Ярдәмче программның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү**

Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программа чараларын финанслау күләме 38 187 588,18 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 5 207 196,08 мең сум;
2015 ел – 5 613 039,50 мең сум;
2016 ел – 6 028 982,60 мең сум;
2017 ел – 5 334 592,50 мең сум;
2018 ел – 5 334 592,50 мең сум;
2019 ел – 5 334 592,50 мең сум;
2020 ел – 5 334 592,50 мең сум.

Финанслау күләмнәре, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, фараз характерында була.»;

ярдәмче программага 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кararга теркәлә);

«2014 – 2020 елларга гомуми белем бирүне, инклюзив белем бирүне кертеп, үстерү һәм бу өлкә хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программа исеме | 2014 – 2020 елларга гомуми белем бирүне, инклюзив белем бирүне кертеп, үстерү һәм бу өлкә хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчысы – яраштыручысы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| Ярдәмче программаның дәүләт заказчылары | Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы,<br>Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| Ярдәмче программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы,<br>Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы,<br>Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| Ярдәмче программа максаты | Балаларга гомуми белем бирү системасында мәгариф программаларын уку-укыту нәтиҗәләре, социальләшү нәтиҗәләренең заманча сыйфатына ирешүгә юнәлдерелгән модернизацияләү һәм, федераль дәүләт мәгариф стандартын тормышка ашыру өчен, уңай шартлар булдыру, энергия саклау процедураларын кертеп |
| Ярдәмче программа бурычлары | Халыкның гомуми белем бирү хезмәтләреннән тигез файдалана алуын тәэмин иткән мәгариф челтәрен һәм финанс-икътисадый механизмнар формалаштыру;<br>гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның алга таба укуга һәм югары технологияле икътисадтагы эшчәнлеккә әзерлеген тәэмин итү өчен, белем бирү эчтәлеген һәм белем бирү мохитен модернизацияләү;<br>педагогик кадрлар составын һәм компетенцияләрен яңарту, педагогларны эш сыйфатын күтәрүгә һәм өзлексез һөнәри |

| | |
|---|---|
| | үсүгә мотивлаштыру механизмнарын булдыру;<br>энергетика ресурсларын һәм суны куллануны киметүгә юнәлдерелгән оештыру һәм техник чаралар үткәрү |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары | 2014 – 2020 еллар |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программа чараларын финанслау күләмнәре 124 413 528,04 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 17 205 591,64 мең сум;<br>2015 ел – 18 902 517,80 мең сум;<br>2016 ел – 18 463 947,00 мең сум;<br>2017 ел – 17 460 367,90 мең сум;<br>2018 ел – 17 460 367,90 мең сум;<br>2019 ел – 17 460 367,90 мең сум;<br>2020 ел – 17 460 367,90 мең сум* |
| Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары) | Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2020 елга түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә укый торган гомуми белем бирү оешмалары укучыларының чагыштырма авырлыгын 98 процентка кадәр арттырырга;<br>гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының гомуми санында 30 яшькәчә укытучылар санының чагыштырма авырлыгын 18 процентка кадәр арттырырга;<br>уку зыянлы булмаган инвалид балаларның гомуми санында, дистанцион мәгариф технологияләреннән файдаланып, өйдә гомуми белем бирү программалары буенча укучы инвалид балалар санының чагыштырма авырлыгын 100 процент дәрәҗәсендә сакларга;<br>балаларга гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренең гомуми санында соңгы 3 ел эчендә квалификациясен күтәргән яки яңадан һөнәри әзерлек үткән дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү |

| | |
|---|---|
| | оешмалары җитәкчеләре санының чагыштырма авырлыгын 11,3 процент дәрәҗәсендә сакларга;<br>гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның гомуми санында төрле дәрәҗәдәге олимпиадалар һәм конкурсларда катнашучы гомуми белем бирү программалары буенча укучылар санының чагыштырма авырлыгын 46 процентка кадәр арттырырга;<br>дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү оешмаларында математика буенча уртача балл – 60,3 балл белән бердәм дәүләт имтиханы (алга таба – БДИ) нәтиҗәләренә;<br>дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү оешмаларында рус теле буенча уртача балл – 68,2 балл белән БДИ нәтиҗәләренә;<br>мәктәп укучыларының гомуми санында төп заманча таләпләр нигезендә укырга мөмкинлек бирелгән мәктәп укучылары өлешен 92 процентка кадәр арттырырга;<br>ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган, шул исәптән туган булмаган затларга (тәрбиягә алган гаиләләргә, уллыкка (кызлыкка), опекага (попечительлеккә), гаилә балалар йортларына һәм патронат гаиләләргә) бирелгән, барык төрдәге дәүләт (муниципаль) учреждениеләрендә булган балалар өлешен 98,8 процент дәрәҗәсендә сакларга;<br>махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләренең җиһазлар белән тәэмин ителешен 70 процентка кадәр арттырырга;<br>махсус (коррекцияле) мәгариф учреждениеләренең җиһаз һәм инвентарь белән тәэмин ителешен 85 процентка кадәр арттырырга;<br>гомуми белем бирә торган мәгариф оешмаларының автоматлаштырылган янгын сигнализациясе белән тәэмин ителешен 100 процент дәрәҗәсендә;<br>10 – 11 сыйныф укучыларының гомуми санынннан югары сыйныф укучыларына |

| | |
|---|---|
| | профильле белем бирүне 76,1 процентка кадәр арттырырга;<br>9 сыйныф укучыларына профиль белем бирүгә әзерлекне 99 процент дәрәҗәсендә сакларга;<br>гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре һәм педагогик хезмәткәрләренең гомуми санында федераль дәүләт мәгариф стандартлары нигезендә эшләү өчен квалификация күтәргән һәм (яки) яңадан һөнәри әзерлек үткән гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре һәм педагогик хезмәткәрләре өлешен 99,8 процентка кадәр арттырырга;<br>дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү оешмаларының гомуми санында заманча укыту таләпләренә туры килә торган дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү оешмалары өлешен 100 процентка кадәр арттырырга;<br>Татарстан Республикасында уртача айлык эш хакына карата гомуми белем бирү оешмалары педагогик хезмәткәрләренең уртача айлык эш хакы мөнәсәбәтен 100 процент дәрәҗәсендә сакларга;<br>Татарстан Республикасында уртача айлык эш хакына карата ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга социаль хезмәтләр күрсәтүче белем бирү оешмалары педагогик хезмәткәрләренең уртача айлык эш хакы мөнәсәбәтен 100 процентка кадәр арттырырга;<br>электр энергиясен чагыштырмача тотуны (гомуми мәйданның 1 кв.метрына исәпләгәндә) 18,34 кВт×сәг/кв.метрга кадәр киметергә;<br>җылылык энергиясен чагыштырмача тотуны (гомуми мәйданның 1 кв.метрына исәпләгәндә) 0,135 Гкал/кв.метрга кадәр киметергә;<br>салкын суны чагыштырмача тотуны (1 кешегә исәпләгәндә) 43,7 куб.метр/кешегә кадәр киметергә; |

| | |
|---|---|
| | кайнар суны чагыштырмача тотуны (1 кешегә исәпләгәндә) 5,37 куб.метр/кешегә кадәр киметергә;<br>табигый газны чагыштырмача тотуны (1 кешегә исәпләгәндә) 211,86 куб.метр/ кешегә кадәр киметергә;<br>җайлаштырылган белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган оешмаларның гомуми санында федераль дәүләт мәгариф стандартлары нигезендә сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучыларның белем алуы өчен заманча матди-техник шартлар булдырылган җайлаштырылган белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган оешмалар өлешен 28 процентка кадәр арттырырга;<br>укытучыларның гомуми санында предметара технологияләр буенча укыту методикасын үзләштергән һәм аны белем бирү процессында гамәлгә ашыра торган укытучылар өлешен 43 процентка кадәр арттырырга;<br>акчалата бүләкләү бирелгән иң яхшы укытучылар санын 26 кешегә кадәр арттырырга;<br>гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының гомуми санында гомуми белем бирү оешмаларының 35 яшькәчә укытучылары санының чагыштырма авырлыгын 26,5 процентка кадәр арттырырга;<br>төбәк гомуми белем бирү системаларының гомуми санында уку елы йомгаклары буенча белем бирүдә түбән нәтиҗәләр күрсәткән гомуми белем бирү оешмаларында һәм уңай булмаган социаль шартларда эшли торган гомуми белем бирү оешмаларында белем бирү сыйфатын күтәрү чаралары эшләнгән һәм гамәлгә ашырыла торган төбәк гомуми белем бирү системалары өлешен 60 процентка арттырырга;<br>сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чик- |

| | |
|---|---|
| | ләнгән балалар белән эшләүче педагогик хезмәткәрләрнең гомуми санында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид укучыларга белем бирү мәсьәләләре буенча яңадан әзерлек үткән яки квалификациясен күтәргән гомуми белем бирү оешмалары педагогик хезмәткәрләре өлешен 100 процентка кадәр арттырырга |

* Финанслау күләмнәре, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, фараз характерында була.»;

ярдәмче программаның 2 бүлегендә:

6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Федераль дәүләт мәгариф стандартларын гамәлгә кертү (шул исәптән 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының «Мәктәп инициативаларына һәм челтәр проектларына конкурс ярдәме күрсәтү аша яңа технологияләр һәм укыту һәм тәрбия эчтәлеген эшләү өчен инновацион программаларны гамәлгә ашыра торган мәктәпләр челтәрен булдыру» дигән 2.3 чарасын һәм «Билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепциясен эшләү, төбәк мәгарифне үстерү программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә технологияләрне һәм укыту эчтәлеген модернизацияләү» дигән 2.4 чарасын финанслашу)

Яңа федераль дәүләт мәгариф стандартларын гамәлгә кертү гомуми белем бирү эчтәлеген яңарту һәм аны алу шартларын модернизацияләүнең төп механизмы булачак.

Яңа федераль дәүләт мәгариф стандартларының нигезен тәшкил итүче булып башлангыч, төп, урта (тулы) гомуми белем бирү буенча төп мәгариф программаларын үзләштерү нәтиҗәләренә таләпләр тора. Яңа федераль дәүләт мәгариф стандартлары белем бирү нәтиҗәләре турындагы күзаллауны шактый киңәйтә һәм предметлар нәтиҗәләрен нормалаштыруга гына түгел, көтелә торган перспективаларны һәм шәхес, гаилә, җәмгыять һәм дәүләтнең таләпләрен килештерү, шулай ук баланың тиешле яшендәге үсеше хакындагы заманча фәнни күзаллаулар нигезендә формалаштырылган метапредмет һәм шәхси нәтиҗәләргә ирешүгә дә юнәлдерә. Әлеге яңа нәтиҗәләргә ирешү адекват матди-техник шартлар гына түгел, педагоглар эшчәнлегендә һәм аны бәяләү системасында әһәмиятле үзгәрешләр таләп итәчәк.

Башлангыч мәктәп баскычында башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандартлары (алга таба – БГББ ФДМС) нигезендә укый һәм үз эшчәнлегеңне оештыра белү нигезен тәшкил итә торган төп компетенцияләрне үзләштерүне тәэмин иткән универсаль уку-укыту гамәлләрен формалаштыру зур

әһәмияткә ия. Бу башлангыч мәктәптә педагогларга үз-үзеңне оештыру һәм үз-үзеңне бәяләүне үстерү технологияләрен үзләштерергә кирәк дигәнне аңлата.

Төп мәктәп баскычында төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандартлары (алга таба – ТГББ ФДМС) нигезендә укучыларның үз-үзләрен үстерү һәм шәхси үзбилгеләнү сәләтен формалаштыруга, белем алу максатларын мөстәкыйль билгеләү һәм аларга ирешү юлларын планлаштыру, укытучы һәм яшьтәшләр белән уку-укыту хезмәттәшлеген һәм уртак эшчәнлекне оештыру осталыкларына аеруча игътибар бирелә.

Әлеге нәтиҗәләргә ирешү үз-үзеңне төрле өлкәләрдә сынап карауны, интенсив аралашуны, гамәли социаль тәҗрибә алуны күздә тоткан яшүсмерләрнең социаль һәм уку-укыту эшчәнлегенең яңа формаларын гамәлгә кертүне таләп итә.

Югары сыйныфларда белем бирү нәтиҗәләре арасында үзәк урынны индивидуаль белем траекториясен төзү сәләте, уку-тикшеренү, проект һәм социаль эшчәнлек күнекмәләре алып тора. Моның өчен урта (тулы) гомуми белем бирү баскычында югары сыйныф укучыларына уку профиленә бәйле уку курсларын сайлау мөмкинлеге тәэмин ителәчәк.

Уку нәтиҗәләрен саклау һәм куллануның шәхсиләштерелгән механизмнарын эшләү тәэмин ителәчәк.

Республикада өченче ел Татарстан Республикасының гомуми белем бирү ФДМСна[1] күчүнең перспективалы планы нигезендә яңа мәгариф стандартларына күчү гамәлгә ашырыла:

**Татарстан Республикасының гомуми белем бирү ФДМСна күчүнең перспективалы планы**

| Уку елы | БГББ ФДМС[2], түбәндәгеләр саны | | | ТГББ ФДМС[3], түбәндәгеләр саны | | | У(Т)ГББ ФДМС[4], түбәндәгеләр саны | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | МО[5] | укучы-лар | сый-ныф-лар | МО | укучы-лар | сый-ныф-лар | МО | укучы-лар | сый-ныф-лар |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 2012/2013 | 1 536 | 83 193 | 5 251 | 21 | 1 830 | 65 | 0 | 0 | 0 |
| 2013/2014 | 1 536 | 95 346 | 6 172 | 79 | 6 137 | 245 | 0 | 0 | 0 |
| 2014/2015 | 1 550 | 155 481 | 7 775 | 270 | 18 258 | 746 | 0 | 0 | 0 |
| 2015/2016 | Х | Х | Х | 1 339 | 55 431 | 2 978 | 0 | 0 | 0 |
| 2016/2017 | Х | Х | Х | 1 299 | 89 539 | 4 853 | 0 | 0 | 0 |
| 2017/2018 | Х | Х | Х | 1 303 | 121 761 | 6 646 | 29 | 1 730 | 68 |
| 2018/2019 | Х | Х | Х | 1 303 | 151 032 | 8 288 | 84 | 4 990 | 208 |
| 2019/2020 | Х | Х | Х | 1 304 | 178 887 | 9 854 | 301 | 13 153 | 588 |
| 2020/2021 | Х | Х | Х | 1 304 | 185 150 | 10 303 | 1 140 | 42 375 | 2 346 |

[1] ФДМС – федераль дәүләт мәгариф стандартлары;
[2] БГББ ФДМС – башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандарты;
[3] ТГББ ФДМС – төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандарты;
[4] У(Т)ГББ ФДМС – урта (тулы) гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандарты;
[5]МО – мәгариф оешмалары.

2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының «Мәктәп инициативаларына һәм челтәр проектларына конкурс ярдәме күрсәтү аша яңа технологияләр һәм укыту һәм тәрбия эчтәлеген эшләү өчен инновацион программаларны гамәлгә ашыра торган мәктәпләр челтәрен булдыру» дигән 2.3 чарасы (алга таба – МҮФМП 2.3 нче чарасы) кысаларында «Гомуми белем бирү системасында мәгариф инновацияләренең илкүләм инкубаторын төзү» комплекслы проектын гамәлгә ашыру, шулай ук мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирүнең, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандартларын гамәлгә кертүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру күздә тотыла.

Яңа мәгариф технологияләрен гамәлгә кертүгә һәм белем бирү эчтәлеген яңартуга булышлык күрсәтү чаралары белән, шулай ук хосусый-дәүләт партнерлыгы механизмнары ярдәме күрсәтеләчәк мәгариф инфраструктурасын камилләштерүне тәэмин итү аша хәзерге заман белем бирү мохитен үстерү өчен шартлар тудыру, мәгариф һәм фән оешмаларының инновацион методик челтәрләрен һәм консорциумнарын төзүне стимуллаштыру юлы белән инновацион тәҗрибә белән уртаклашу күздә тотыла.

Моннан тыш, әлеге бурычның мөһим элементы булып актуаль проблемалар буенча мәгариф өлкәсендә, шул исәптән сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларга белем бирү өлкәсендә инновацияләргә ярдәм күрсәтү тора.

Россия Федерациясендә Математика белемен үстерү концепциясен, шулай ук башка предмет өлкәләрен үстерү концепцияләрен гамәлгә ашыру тәэмин ителәчәк.

Гомуми белем бирүнең яңа эчтәлеген һәм технологияләрен гамәлгә кертү өчен кирәкле шартлар булып компетентлы педагогик һәм җитәкчелек кадрлары тора.

Шуңа күрә МҮФМП 2.3 нче чарасы кысаларында гомуми белем бирү оешмалары педагогик хезмәткәрләренең һөнәр дәрәҗәсен күтәрү буенча чаралар тормышка ашырылачак, шул исәптән педагог һәм җитәкченең һөнәр стандартларын гамәлгә кертү тәэмин ителәчәк, педагогик лидерлык, нәтиҗәле укыту, укучыларның һөнәр берләшмәләренең заманча модельләре апробацияләнәчәк.

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан, гомуми белем бирүнең төп мәгариф программаларын гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмалары өчен 1,0 млн.сум күләмендә грант бирү максатларында, конкурс нигезендә сайлап алулар игълан ителәчәк.

Грантлар МҮФМП 2.3 нче чарасын тормышка ашыру кысаларында түбәндәге юнәлешләр буенча бирелә:

«Инициативалы инновацион проект»;

«Мәктәп китапханәсен үстерү»;

«Укучыларга тәрбия бирү һәм аларның социальләшүе буенча инновацион программаларны тормышка ашыру»;

«Башлангыч гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын тормышка ашырганда белем бирү эчтәлегенең яңа элементларын һәм тәрбия системаларын, яңа педагогик технологияләрне эшләү, апробацияләү, гамәлгә кертү»;

«Мәктәп эчендә сыйфатны бәяләү системасы».

2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының «Билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепциясен эшләү, төбәк мәгарифне үстерү программаларына ярдәм күрсәтү һәм челтәр методик берләшмәләренә булышлык күрсәтү юлы белән яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә технологияләрне һәм укыту эчтәлеген модернизацияләү» дигән 2.4 чарасы кысаларында (алга таба – МҮФМП 2.4 нче чарасы) «Башлангыч, төп һәм урта гомуми белем бирүнең, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандартларын гамәлгә кертүгә ярдәм күрсәтү» комплекслы проекты тормышка ашырылачак.

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын һәм МҮФМП 2.4 нче чарасын гамәлгә ашыру максатларында, республикада ГББ ФДМС һәм СМЧ ФДМС нигезендә гомуми белем бирү оешмаларының алдынгы укыту методикаларын һәм иң яхшы эш практикасын максатчан формалаштыру, билгеләү, апробацияләү һәм алга таба уртаклашуны тәэмин итүгә ярдәм күрсәтелә. Белем бирү эшчәнлеген алга таба камилләштерүне тәэмин итүгә игътибар бирелә, аеруча аны гамәлгә ашыру шартларын яңарту өлешендә, шул исәптән сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен. Әлеге шартлар мәгариф оешмаларында укыту эчтәлеген, чараларын һәм формаларын яңарту өчен заманча инновацион белем бирү технологияләреннән һәм мөмкинлекләрдән файдалануны тәэмин итәргә тиеш.

Федераль дәүләт мәгариф стандартларының нигезен тәшкил итүче булып башлангыч, төп, урта гомуми белем бирү буенча төп мәгариф программаларын үзләштерү нәтиҗәләренә таләпләр тора. Федераль дәүләт мәгариф стандартлары белем бирү нәтиҗәләре турындагы күзаллауны шактый киңәйтә һәм предметлар нәтиҗәләренә генә түгел, көтелә торган перспективаларны һәм шәхес, гаилә, җәмгыять һәм дәүләтнең таләпләрен килештерү, шулай ук баланың тиешле яшендәге үсеше хакындагы заманча фәнни күзаллаулар нигезендә формалаштырылган метапредмет һәм шәхси нәтиҗәләргә ирешүгә дә юнәлдерә. Әлеге яңа нәтиҗәләргә ирешү адекват матди-техник шартлар гына түгел, билгеле өлкәләрне модернизацияләү концепциясен эшләү юлы белән укыту технологияләрен һәм эчтәлеген модернизацияләүне, педагоглар эшчәнлегендә һәм аны бәяләү системасында әһәмиятле үзгәрешләр таләп итәчәк.

Башлангыч мәктәп баскычында башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә укый һәм үз эшчәнлегеңне оештыра белү нигезен тәшкил итә торган төп компетенцияләрне үзләштерүне тәэмин иткән универсаль уку-укыту гамәлләрен формалаштыру зур әһәмияткә ия. Бу башлангыч мәктәптә педагогларга үз-үзеңне оештыру һәм үз-үзеңне бәяләүне үстерү технологияләрен үзләштерергә кирәк дигәнне аңлата.

Төп мәктәп баскычында төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә укучыларның үз-үзләрен үстерү һәм шәхси үзбилгеләнү сәләтен формалаштыруга, белем алу максатларын мөстәкыйль билгеләү һәм аларга ирешү юлларын планлаштыру, укытучы һәм яшьтәшләр белән уку-укыту хезмәттәшлеген һәм уртак эшчәнлекне оештыру осталыкларына аеруча игътибар

бирелә. Әлеге нәтиҗәләргә ирешү үз-үзеңне төрле өлкәләрдә сынап карауны, интенсив аралашуны, гамәли социаль тәҗрибә алуны күздә тоткан яшүсмерләрнең социаль һәм уку-укыту эшчәнлегенең яңа формаларын гамәлгә кертүне таләп итә.

Югары сыйныфларда белем бирү нәтиҗәләре арасында үзәк урынны индивидуаль белем траекториясен төзү сәләте, уку-тикшеренү, проект һәм социаль эшчәнлек күнекмәләре алып тора. Моның өчен урта гомуми белем бирү баскычында югары сыйныф укучыларына уку профиленә бәйле уку курсларын сайлау мөмкинлеге тәэмин ителәчәк. Уку нәтиҗәләрен саклау һәм куллануның шәхсиләштерелгән механизмнарын эшләү тәэмин ителәчәк.

МҮФМП 2.4 нче чарасын тормышка ашыру үзенчәлеге булып төп гомуми белем бирү программаларын һәм җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны тиешле кадрлар, матди-техник һәм мәгълүмати-методик шартлар белән тәэмин итү таләбе тора. Республикада массакүләм гомуми белем бирү мәктәпләре шартларында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларны интеграцияләнгән укытуны гамәлгә кертү буенча актив эш алып барыла.

Төп программа чаралары булып түбәндәгеләр тора:

1. Табигый-фәнни циклдагы предметларны модернизацияләү концепциясен эшләү.

2. Төп гомуми белем бирү программаларын һәм җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмаларының матди-техник базасын яңарту.

3. ГББ ФДМС һәм СМЧ ФДМС таләпләре нигезендә уку-укыту-тәрбия бирү процессын камилләштерү.

4. Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучыларның ФДМС гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гомуми белем бирү һәм махсус (коррекцияле) мәктәпләрнең җитәкчеләре һәм педагогик хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан һөнәри әзерләү.

5. Оешмаларны заманча тернәкләндерү җиһазлары белән тәэмин итү һәм тернәкләндерү хезмәтләре исемлеген киңәйтү.

6. Төрле сәламәтлек төркемендәге укучыларның уңышлы социальләшүе өчен шартлар тудыру.»;

14 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

19 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Авыр социаль шартларда эшли торган мәктәпләргә ярдәм күрсәтү (шул исәптән 2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының «Белем бирүдә түбән нәтиҗәләр күрсәткән мәктәпләрдә һәм уңай булмаган социаль шартларда эшли торган мәктәпләрдә төбәк проектларын тормышка ашыру юлы белән белем бирү сыйфатын күтәрү һәм аларның нәтиҗәләре белән бүлешү» дигән 2.2 нче чарасын финанслашу)

Татарстан Республикасында югары дәрәҗәдә гомуми белем бирү тәэмин ителгән. «Мәгариф» өстенлекле илкүләм проекты, «Безнең яңа мәктәп» милли белем бирү инициативасы, Мәгарифне үстерү федераль максатчан программасы, гомуми

белем бирүнең төбәк системаларын модернизацияләү проекты кысаларында төрле категорияләрдәге укучыларга сыйфатлы белем бирүдән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар гамәлгә ашырыла.

Әмма барлык белем бирү баскычларында белем бирүдә тотрыклы рәвештә түбән нәтиҗәләр күрсәткән мәктәпләр (авыл мәктәпләре дә, шәһәр мәктәпләре дә) сегменты аерылып чыга. Аларда башлыча түбән социаль-икътисадый статуслы гаиләләрдән, авыр тормыш хәлендә калган гаиләләрдән һәм мигрантлар гаиләләреннән торган контингент урын ала. Мондый контингент белән эшли торган мәктәпнең аңа тышкы мохит каршылыкларын җиңеп чыга алырга мөмкинлек бирә торган ресурслары һәм эчке потенциалы булырга тиеш. Ләкин гамәлдә катлаулы контингент белән эшли торган мәктәпләрнең нәтиҗәле эшчәнлек өчен кирәкле ресурслары булмый. Нәтиҗә буларак, мәктәпләрнең әлеге төркеме социаль лифт функциясен башкарудан туктый, социаль дифференциация чыгара һәм ныгыта башлый.

Катлаулы контингент белән һәм авыр шартларда эшли торган мәктәпләргә, шул исәптән белем бирүдә түбән нәтиҗәләр күрсәткән мәктәпләргә ярдәм итү аларны кризис хәлендә булган мәктәпләр һәм куркыныч ситуациядә булган мәктәпләр буларак идентификацияләргә һәм бүлергә, ярдәм күрсәтүнең иң нәтиҗәле һәм адреслы формаларын билгеләргә мөмкинлек бирә торган ышанычлы ысуллар һәм инструментлар эшләүне күздә тота.

Катлаулы контингент белән һәм авыр шартларда эшли торган мәктәпләргә, шул исәптән белем бирүдә түбән нәтиҗәләр күрсәткән мәктәпләргә ярдәм итү комплекслы характерда була, ул мәктәп белән идарә итү, мәктәп климаты, мәктәп һәм сыйныф дәрәҗәсендә сыйфатны бәяләү, укыту, педагогларның һөнәри үсеше, ата-аналар һәм җирле берләшмәләр белән хезмәттәшлек итү кебек өлкәләрдә үзгәрешләрне күздә тота. Даими финанслауга нәтиҗәле эш режимына күчәргә кирәкле начар эшли торган мәктәпләр өчен нәтиҗәләрне яхшырту программаларын максатчан финанслау өстәлә ала. Монда мәктәпнең төгәл бурычлары, аларның казанышлары һәм мәгариф идарәсе органнары тарафыннан акчадан файдалану нәтиҗәлелеге мониторингы, ата-аналар һәм җирле берләшмәләр алдында хисап тоту күздә тотыла.

Мәктәпләргә ярдәм күрсәтү стратегиясендә укучылар һәм персонал өчен башка ресурслардан киң файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү күздә тотылырга тиеш: укучыларга өстәмә белем бирү һәм психологик ярдәм күрсәтү, персоналның һөнәри үсеше һәм мәктәп җитәкчелегенең идарәчелек компетенцияләрен күтәрү өчен мәктәпләр һәм һөнәри берләшмәләр белән партнерлык, уку-укыту әсбаплары һәм электрон белем бирү ресурслары, шулай ук укытучыларга бергәләп планлаштыру һәм челтәр эше, тьюторлык өчен кирәкле өстәмә вакыт.

Мөһим бурыч булып әлеге категориядәге мәктәпләрдә эшләү өчен югары квалификацияле җитәкчеләрне һәм укытучыларны җәлеп итү, аларга финанс һәм карьера стимуллары тудыру аша мәктәпкә беркетү буенча ярдәм күрсәтү һәм чараларны тормышка ашыру тора.

Белем бирү сыйфатын күтәрүне билгели торган төп корректировкалар укыту баскычында була. Шуңа күрә бөтен мәктәпләр персоналы һөнәри үсешнең индивидуаль планнарына нигезләнгән һәм әлеге мәктәпләр контингенты белән эшләү өчен махсус модульләрне һәм курсларны, шундый ук мәктәпләрдән килгән коллегалар

белән тәҗрибә уртаклашуны, стажировкаларны, шулай ук даими консультацияләр бирү һәм коучинг ярдәме күрсәтүне күздә тоткан квалификация күтәрү программаларына җәлеп ителәчәк.

Катлаулы контингент белән һәм авыр шартларда эшли торган мәктәпләргә, шул исәптән белем бирүдә түбән нәтиҗәләр күрсәткән мәктәпләргә ярдәм күрсәтү программаларын эшләү һәм тормышка ашыруга ата-аналар, бизнес-структуралар, һөнәри берләшмәләр җәлеп ителәчәк.

Катлаулы контингент белән һәм авыр шартларда эшли торган мәктәпләргә, шул исәптән белем бирүдә түбән нәтиҗәләр күрсәткән мәктәпләргә ярдәм күрсәтү программаларының сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген бәяләү өчен, мәктәп культурасы һәм белем бирү мохите торышын билгели торган сан (БДИ, ДЙА нәтиҗәләре, олимпиадаларда һәм конкурсларда катнашу һ.б.) һәм сыйфат ягыннан бәяләүне күздә тоткан катнаш методология кулланылачак. Укучыларның төрле төркемнәре өчен индивидуаль мөмкинлекләрне һәм көтелгәннәрне исәпкә алып, үсешне күздә тоту мөһим.

Ярдәмче программа кысаларында түбәндәге чаралар комплексы гамәлгә ашырылачак:

Катлаулы контингент белән һәм авыр шартларда эшли торган мәктәпләрне, шул исәптән белем бирүдә түбән нәтиҗәләр күрсәткән мәктәпләрне билгеләүгә юнәлдерелгән мониторинг тикшеренүләре һәм эшчәнлек шартларын, идарәчелек һәм педагогик потенциалын комплекслы бәяләүне үткәрү.

Һәркем файдалана алырлык түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем алуга гражданнар хокукларының дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә муниципаль районнар һәм шәһәр округлары, шул исәптән белем бирүдә түбән нәтиҗәләр күрсәткән мәктәпләр бюджетларына бюджет финанславы нормативларын һәм субвенцияләрне исәпләү методикасына, федераль дәрәҗәдә эшләнгән тиешле методик рекомендацияләрне исәпкә алып, үзгәреш кертү.

Катлаулы контингент белән һәм авыр шартларда эшли торган гомуми белем бирү оешмалары тарафыннан өстәмә белем бирү программаларын (тәэмин итү программалары) гамәлгә ашыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт (муниципаль) йөкләмәсен формалаштыру.

Алар кысаларында мәктәпләр гомумәктәп һәм укучыларның шәхси нәтиҗәләрен күтәрү йөкләмәсен алган белем бирү нәтиҗәләрен яхшырту программаларын эшләүне һәм аларга ярдәм күрсәтүне тәэмин итү.

Муниципаль программалар кысаларында мәктәпләрнең ресурслар базасын муниципаль берәмлек буенча уртачадан түбән булмаган дәрәҗәгә җиткерү буенча адреслы чараларны тормышка ашыру.

Мәктәпләрнең контингент буенча ачык күренеп торган катламнарга бүленеше барлыкка килүен булдырмый торган белем бирү челтәрләрен формалаштыруга һәм мәктәпләрне комплектлауга инновацион якын килү юлларын гамәлгә кертү.

Катлаулы контингент белән эшли торган һәм белем бирүдә түбән нәтиҗәләр күрсәткән мәктәпләрнең нәтиҗәләрен яхшырту программаларын эксперт-консультация ярдәме белән тәэмин итү буенча методик хезмәтләрне гамәлгә ашыру.

Мәктәпләр һәм педагогларны һөнәри үстерү белән идарә итү практикасына нәтиҗәләр буенча идарә итү методларын кертү.

Укытучыларга хезмәт өчен түләү мәсьәләләрен җайга сала торган норматив актларга укытучының эш хакының база өлешен хисаплаганда укучылар контингентының катлаулылыгын тасвирлый торган параметрларны исәпкә алуны тәэмин иткән; укытучыларның эш вакытын исәпләгәндә артта калучы укучылар белән индивидуаль дәресләргә вакытны исәпкә алу тәртибен билгели торган үзгәрешләр кертү.

Югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары базасында белем бирүдә түбән нәтиҗәләр күрсәткән мәктәпләрне үстерү программаларын тәэмин итү функцияләрен бшкаручы эксперт-консультантларны әзерләү.

Катлаулы контингент белән һәм авыр шартларда эшли торган гомуми белем бирү оешмалары директорларының квалификация күтәрү буенча лидерлык компетенцияләрен формалаштыруга юнәлдерелгән программаларны, коучинг, остазлык һәм коллегалар белән хезмәттәшлек итү программаларын кертеп, тормышка ашыру.

Катлаулы контингент белән эшли торган мәктәпләр педагогларының квалификациясен күтәрү һәм яңадан һөнәри әзерләү буенча укучыларның шәхси үсешен тәэмин итү һәм бәяләү, аерым ихтыяҗлары булган балалар белән эшләү, уку-укыту һәм тәрбия проблемалары өлкәсендә компетентлыгын арттыруга юнәлдерелгән программаларны гамәлгә ашыру.

Катлаулы контингент белән һәм авыр шартларда эшли торган мәктәпләрдә, шул исәптән белем бирүдә түбән нәтиҗәләр күрсәткән мәктәпләрдә эшләү өчен директорларны конкурс нигезендә сайлап алу, аларга системалы рәвештә ярдәм күрсәтүне, эшчәнлекләрен стимуллаштыруны тәэмин итү, шул исәптән җитәкченең эш хакы һәм мәктәп контингентының катлаулылыгы, нәтиҗәләрне яхшырту программаларын тормышка ашыру динамикасы арасында элемтә урнаштыру исәбеннән.

Мәктәп һәм методик һөнәри берләшмәләр оештыруны һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүне стимуллаштыру буенча чараларны тормышка ашыру.

Дистанцион белем бирү программаларын гамәлгә ашыру.

Белем бирүдә түбән нәтиҗәләр күрсәткән мәктәпләрнең әйдәп баручы мәктәпләр белән администрациянең һәм педагогларның тәҗрибә уртаклашуын, партнер мәктәпләр сыйныфларында укытуны үз эченә алган партнерлыгын оештыру өчен норматив, финанс, оештыру һәм кадрлар ягыннан шартлар тәэмин итү.

Партнерлык программаларын тормышка ашыруга грантларны гамәлгә кертү.

Дәресләр өчен вакытның өстәмә ресурсларыннан файдалануда мәктәпнең мөмкинлекләрен киңәйтү чараларын гамәлгә ашыру: тулы көн мәктәбе, белем бирү лагерьләре, кышкы һәм җәйге мәктәпләр һ.б.

Көчле кадрлар ресурслары булган мәктәпләр базасында БДИга әзерләнүнең муниципальара программаларына ярдәм күрсәтү.

Катлаулы контингент белән һәм авыр шартларда эшли торган мәктәпләрнең, шул исәптән педагогларның һәм мәктәп укучыларының, муниципаль һәм

республика дәрәҗәләрендәге конкурсларда һәм мәктәпара проектларда катнашуын стимуллаштыру һәм ярдәм итү.

Катлаулы контингент белән һәм авыр шартларда эшли торган мәктәпләргә җәмәгатьчелек катнашында коллегиаль идарә органнарын формалаштыруда, җирле берләшмәне мәктәпләр эшчәнлегенә җәлеп итү программаларын эшләүдә һәм тормышка ашыруда ярдәм күрсәтү.

Катлаулы контингент белән һәм авыр шартларда эшли торган мәктәпләрнең, шул исәптән белем бирүдә түбән нәтиҗәләр күрсәткән мәктәпләрнең коллегиаль идарә органнары әгъзаларын – иҗтимагый идарәчеләрне аларның нәтиҗәле эш режимына күчү программаларын эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга җәлеп ителешен көчәйтүгә, кирәкле компетенцияләрне үзләштерүгә юнәлдерелгән махсус программалар буенча әзерләүне оештыру.

Гаиләләрне балаларның белем алуына җәлеп итү программаларын эшләү һәм тормышка ашыру, педагогларның гаиләләргә баруын, гаиләләр өчен консультацияләр үткәрүне кертеп һ.б.

Катлаулы контингент белән һәм авыр шартларда эшли торган мәктәпләрдә, шул исәптән белем бирүдә түбән нәтиҗәләр күрсәткән мәктәпләрдә эшләү өчен югары уку йортлары студентларын һәм аспирантларын тьюторлар сыйфатында җәлеп итү.

Республика белем бирү сыйфатын бәяләү системасына мәктәпләр һәм педагоглар эшчәнлеген бәяләгәндә контекст күрсәткечләрен исәпкә алу инструментарием һәм процедураларын кертү, шул исәптән социаль иминлек индексларыннан файдаланып.

Укучыларның индивидуаль үсешен билгеләүгә һәм бәяләү мәгълүматларыннан укытуны яхшырту өчен файдалануга юнәлдерелгән мәктәп эчендә белем бирү сыйфатын бәяләү системаларын үстерү.

Катлаулы социаль контекстта эшли торган мәктәпләрнең, имин булмаган гаиләләрдәге балаларны укытучы педагогларның казанышлары халык арасында танылуны тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру.

Катлаулы контингент белән һәм авыр шартларда эшли торган мәктәпләр, шул исәптән белем бирүдә түбән нәтиҗәләр күрсәткән мәктәпләр эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итүне оештыру, ул үз эченә түбәндәгеләрне ала:

җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү һәм анализлау;

җәмәгатьчелек игътибарын максатчан аудиторияләр проблемасына юнәлтү;

барлык каналлар буенча коммуникацияләргә комплекслы ярдәм күрсәтү;

җәмәгатьчелек фикере лидерлары пулын формалаштыру, массакүләм мәгълүмат чаралары белән системалы эшне.

2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программасының «Белем бирүдә түбән нәтиҗәләр күрсәткән мәктәпләрдә һәм уңай булмаган социаль шартларда эшли торган мәктәпләрдә төбәк проектларын тормышка ашыру юлы белән белем бирү сыйфатын күтәрү һәм аларның нәтиҗәләре белән бүлешү» дигән 2.2 нче чарасы кысаларында уңай булмаган социаль шартларда эшли торган мәктәпләрдә белем бирү сыйфатын күтәрү механизмнарын эшләү һәм алар белән бүлешү буенча комплекслы проектны тормышка ашыру күздә тотылган.

2017 – 2018 елларга начар эшли торган мәктәпләрне үстерүгә ярдәм итә торган төп чаралар булып түбәндәгеләр тора ала:

1. Эшчәнлек шартларын һәм нәтиҗәләрен, идарәчелек һәм педагогик потенциалын, тулаем мәктәпнең социаль-педагогик мохите торышын комплекслы бәяләү нигезендә начар эшли торган мәктәпләрне билгеләү буенча тикшеренү үткәрү, шулай ук аларны үстерүгә ярдәм иткән мотивацион һәм стимулллаштыручы факторларны өйрәнү.

2. Мәктәпләрнең нәтиҗәләрен яхшыртуны, белем бирү сыйфатын күтәрүне бәяләү механизмнарын һәм инструментларын эшләү.

3. Мәктәпнең социаль-педагогик мохитен үстерү нигезендә катлаулы контингент белән һәм авыр шартларда эшли торган мәктәпләргә, шул исәптән белем бирүдә түбән нәтиҗәләр күрсәткән мәктәпләргә ярдәм күрсәтү буенча республика комплекслы социаль-педагогик проектын (программасын) эшләү һәм тормышка ашыру.

4. Мәктәпнең социаль-педагогик мохите үзенчлекләрен исәпкә алып, начар эшли торган мәктәпләрне үстерү программаларының инвариант һәм вариатив модельләрен эшләү һәм тормышка ашыру.

5. Мәктәпнең социаль-педагогик мохите үзенчәлекләрен исәпкә алу нигезендә катлаулы контингент белән эшли торган һәм белем бирүдә түбән нәтиҗәләр күрсәткән мәктәпләрнең нәтиҗәләрен яхшырту программаларын фәнни-методик һәм эксперт-консультацион тәэмин итү нәтиҗәлелеген арттыру.

6. Катлаулы контингент белән һәм авыр шартларда эшли торган гомуми белем бирү оешмалары директорларының квалификация күтәрү буенча лидерлык компетенцияләрен формалаштыруга юнәлдерелгән өстәмә һөнәри программаларны, коучинг, остазлык һәм коллегалар белән хезмәттәшлек итү программаларын кертеп, әзерләү һәм тормышка ашыру.

7. Катлаулы контингент белән эшли торган мәктәпләр педагогларының квалификациясен күтәрү һәм яңадан һөнәри әзерләү буенча укучыларның шәхси үсешен тәэмин итү һәм бәяләү, аерым ихтыяҗлары булган балалар белән эшләү, уку-укыту һәм тәрбия проблемалары өлкәсендә компетентлыгын үстерүгә юнәлдерелгән өстәмә һөнәри программаларны әзерләү һәм гамәлгә ашыру.

8. Начар эшли торган мәктәпләрне үстерү тәҗрибәсен гомумиләштерү, катлаулы социаль контекстта эшли торган мәктәпләрнең казанышлары халык арасында танылуны тәэмин итү һәм әлеге өлкәдә иң яхшы белем бирү практикалары белән бүлешүнең республика программасын эшләү.»;

22, 26, 27 нче пунктлар үз көчен югалткан дип санарга;

ярдәмче программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү**

Ярдәмче программа чараларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 124 413 528,04 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 17 205 591,64 мең сум;

2015 ел – 18 902 517,80 мең сум;
2016 ел – 18 463 947,00 мең сум;
2017 ел – 17 460 367,90 мең сум;
2018 ел – 17 460 367,90 мең сум;
2019 ел – 17 460 367,90 мең сум;
2020 ел – 17 460 367,90 мең сум.

Финанслау күләмнәре, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, фараз характерында була.»;

ярдәмче программаның 5 бүлегендә таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Күрсәткеч | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. Яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә укый торган гомуми белем бирү оешмалары укучыларының чагыштырма авырлыгы, процент | 33,1 | 56,5 | 53,0 | 63,0 | 73,0 | 89,2 | 98 |
| 2. Гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының гомуми санында 30 яшькәчә укытучылар санының чагыштырма авырлыгы, процент | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 18 | 18 |
| 3. Уку зыянлы булмаган инвалид балаларның гомуми санында, дистанцион мәгариф технологияләреннән файдаланып, өйдә гомуми белем бирү программалары буенча укучы инвалид балалар санының чагыштырма авырлыгы, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 4. Балаларга гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренең гомуми санында соңгы өч ел эчендә квалификациясен күтәргән яки яңадан һөнәри әзерлек үткән дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре санының чагыштырма авырлыгы, процент | 11,3 | 11,3 | 11,3 | 11.3 | 11,3 | 11,3 | 11,3 |
| 5. Гомуми белем бирү программалары буенча укучылар- | 38 | 40 | 42,5 | 44 | 46 | 46 | 46 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ның гомуми санында төрле дәрәҗәдәге олимпиадалар һәм конкурсларда катнашучы гомуми белем бирү программалары буенча укучылар санының чагыштырма авырлыгы, процент | | | | | | | |
| 6. Дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү оешмаларында бердәм дәүләт имтиханы (БДИ) нәтиҗәләре, математика буенча уртача балл | 48,6 | 50,2 | 49,5 | 51,0 | 51,0 | 51,0 | 51,0 |
